Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

12 ноябрь 2020 ел №6

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль
районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Люгдон поселогында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 27 ноябрендә сәгат 09.00 Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлегенең Люгдон поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының билгеләп үтәргә. Халык җыенын шәхси йортта түбәндәге адрес буенча уздырырга: Люгдон поселогы, Лесная урамы, 3 йорт.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: "Сез яшәү урыны буенча Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлегенең Люгдон поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны:

- авыл җирлеге торак пунктларында урам юл челтәрен карап тоту өчен шартлар булдыру кебек эшләр башкаруга юнәлтү белән ризамы?»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Түбән Үрәс авыл җирлегенең башкарма комитеты гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында җирлекнең «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә игълан итәргә.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Үрәс Авыл
җирлеге башлыгы: Р.Х.Шамеев